# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге Элемтә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

22.11.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге уставының 14 статьясы Михайловка авыл советының 2019 елның 14 октяберендәге 7 карары «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәсен раслау турында» нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 22 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Элемтә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә; I, II төркем инвалидлар, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасы студентлары өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән, һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Урманлы, Кооператив, Елга урамнары ут челтәрләрен төзекләндерү һәм техник хезмәт күрсәтү.

-Светодиодлы лампалар, беркеткечләр, тулыландыручы җихазлар сатып алу, килешү буенча түләү;

**2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Кооперати урамындагы су белән тәэмин итуче манараны төзекләндерү ;

-Су манарасы мәйданын төзекләндерү, чистарту, чабу;

-Су сыйфаты буенча лаборатория тикшерүләре үткәрү.

**3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

-Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү;

**4. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту:**

-Урманлы, Кооператив, Елга урамнары юлларын кышкы тоту, су манарасы, ШРП, зыяратка юл ачу;

- Урманлы, Кооператив, Елга урамнары юлларын җәйге тоту;

- Урманлы, Кооператив, Елга урамнарын тигезләү һәм таш салу;

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү һәм ремонтлау:**

- Үлән чабу;
- Корыган, кыргый агачларны кисү.

6. **Зыяратларны төзекләндерү һәм тоту:**

- Элемтә авылында урнашкан зыяраттан чүп түгү;
- Сугыш тәмамлануга 80 еллык юбилей уңаеннан истәлекле такталар сатып алу һәм кую.

7. **Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү:**

- Чүплекләрне бетерү;
- Каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 82 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 50, бу 66% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 33 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 17 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Элемта авыл җирлегенең Михайловка торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авылы җирлеге Элемтә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә; I, II төркем инвалидлар, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасы студентлары өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән, һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә».

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1. **Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Урманлы, Кооператив, Елга урамнары ут челтәрләрен төзекләндерү һәм техник хезмәт күрсәтү.
-Светодиодлы лампалар, беркеткечләр, тулыландыручы җихазлар сатып алу, килешү буенча түләү;

2. **Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Кооперати урамындагы су белән тәэмин итуче манараны төзекләндерү ;
-Су манарасы мәйданын төзекләндерү, чистарту, чабу;
-Су сыйфаты буенча лаборатория тикшерүләре үткәрү.

**3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин иту:**

-Янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү;

**4. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту:**

-Урманлы, Кооператив, Елга урамнары юлларын кышкы тоту, су манарасы, ШРП, зыяратка юл ачу;

- Урманлы, Кооператив, Елга урамнары юлларын җәйге тоту;
- Урманлы, Кооператив, Елга урамнарын тигезләү һәм таш салу;

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү һәм ремонтлау:**

- Үлән чабу;
- Корыган, кыргый агачларны кисү.

**6. Зыяратларны төзекләндерү һәм тоту:**

- Элемтә авылында урнашкан зыяраттан чүп түгү;
- Сугыш тәмамлануга 80 еллык юбилей уңаеннан истәлекле такталар сатып алу һәм кую.

**7. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү:**

- Чүплекләрне бетерү;

Каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Михайловка авыл җирлеге башлыгы ____________ (имза) Н.А. Ращупкина (имзаның аңлатмасы)